ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2024 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында комплекслы чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итүне.

2.2. 2025 елда Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Рәисен, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларны, башка массакүләм чараларны әзерләү һәм үткәрү чорында җәмәгать тәртибен һәм иминлек тәэмин итүне.

2.3. Татарстан Республикасы гавами хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләр, традицион конфессияләрнең дини оешмалары, милли-мәдәни автономияләр белән берлектә экстремистлык һәм террорчылык эшчәнлегенә, бигрәк тә аеруча мөһим инфраструктура объектларына һәм яшәүне тәэмин итү объектларына карата, каршы көрәш өлкәсендә чараларны, ихтимал булган милләтара конфликтларны булдырмау чараларын дәвам итүне.

2.4. Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм башка торак пунктларында җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне, шул исәптән гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар үткәргәндә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларыннан килгән зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе белән берлектә, дәвам итүне.

2.5. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар арасында законсыз миграциягә һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш максатында Татарстан

Республикасында миграция вәзгыятен тикшереп тору өлешендәге эшне дәвам итүне.

2.6. Мәгълүмат технологияләрен кулланып кылына торган җинаятьләрне профилактикалау механизмнарын камилләштерү чараларын күрүне.

2.7. Балигъ булмаганнарны җинаять эшчәнлегенә тартуга каршы көрәш максатында алар арасындагы хокук бозуларны профилактикалау эшен көчәйтүне.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм аны үз вакытында финанслау эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

4. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Муниципаль берәмлекләр территорияләрендә җәмәгать тәртибен саклауны һәм гражданнарның иминлеген оештыру буенча хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне активлаштыруны.

4.2. Хокук саклау юнәлешендәге (экстремистлык һәм террорчылык күренешләренә каршы көрәш, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, хокук бозуларны профилактикалау өлкәләрендәге) муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны һәм аларны үз вакытында финанслауны, шулай ук әлеге программаларның эчтәлеген, «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезләмәләрен исәпкә алып, актуальләштерүне тәэмин итүне.

5. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнарның шәхси иминлеге, аларның акчаларын һәм мөлкәтен саклау мәсьәләләрен аңлатучы, экстремистлык һәм террорчылык юнәлешендәге җинаятьләр әзерләнү яисә кылыну турында билгеле булган фактлар хакында хокук саклау органнарына хәбәр итү ысуллары турында белешмәләр, шулай ук халыкта эчке эшләр органнары эше хакында уңай фикер тудыра торган материаллар бастырып чыгаруны арттыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 185-VII ДС